Аерым объектларның архитектура чишелешләренең иҗади сораулары Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге каршындагы архитектура Советы каравына юнәлдерелергә мөмкин.

## 2. Советның бурычлары һәм функцияләре

2.1. Советның төп бурычы булып түбәндәгеләр тора:
Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы торак пунктларының архитектура, шәһәр төзелеше проблемалары һәм аларны хәл итү юллары, архитектура-сәнгать ягыннан күренеш дәрәҗәсен күтәрү турында фикер алышу.
2.2 Төп бурыч нигезендә Совет түбәндәге функцияләрне башкара:
-архитектура-шәһәр төзелеше үсеше, торак пунктларда төзелеш сыйфатын күтәрү проблемалары буенча тәкъдимнәр әзерли;
-район торак пунктларының архитектура-сәнгать кыяфәтен формалаштыручы күчемсез милек объектлары буенча шәһәр төзелеше таләпләренә туры килү өлешендә проект документациясен килештерү буенча тәкъдимнәр әзерли;
-район торак пунктларының шәһәр төзелеше документларын, шәһәр төзелеше эшчәнлеге регламентларын һәм төзекләндерү, инженерлык һәм транспорт белән тәэмин итү проектларын раслау буенча тәкъдимнәр әзерли;
-әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый ресурсларны рациональ файдалану, саклау һәм торгызу, архитектура, шәһәр төзелеше сәнгате, тарих, мәдәният һәм ландшафт һәйкәлләрен саклау һәм куллану буенча чаралар, шулай ук аларны саклау зоналары проектлары өчен тәкъдимнәр әзерли;
-район торак пунктлары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында тәкъдимнәр чыгара;
-архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-техник прогресс казанышларын кертү буенча тәкъдимнәр чыгара;
- расланган проектларны тормышка ашыруны, шулай ук район торак пунктларын төзү тәҗрибәсен анализлый.

## 3.Хокуклары

Совет түбәндәгеләргә хокуклы:
- билгеләнгән тәртиптә проект һәм төзелеш оешмаларыннан, заказ бирүчеләрдән һәм төзүчеләрдән кирәкле материаллар һәм тәкъдимнәр алырга;
-Совет утырышларына планлаштырылган мәсьәләләрне карау өчен кирәк булган заказчылар, проект, төзелеш һәм башка оешма вәкилләрен, шәхси затларны чакырырга;

Совет карарлары совет рәисе һәм Совет секретаре кул куя торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Бер атна эчендә беркетмәләрнең күчермәләре Совет әгъзаларына, кызыксынган затларга һәм оешмаларга җибәрелә.

Совет утырышлары беркетмәләре 3 ел дәвамында «ЗМР архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесендә сакланырга тиеш.

Советның эш планы районның баш архитекторы тәкъдимнәре, оешмалар һәм физик затларның язмача һәм телдән тәкъдимнәре нигезендә төзелә.

Совет әгъзалары Совет утырышларында катнашырга, ә җитди сәбәпләр аркасында булмаганда, Совет утырышларына үз вәкаләтле вәкилен җибәрергә тиеш.